ГОСУДАРСТВЕННЫЙ
КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ
Ново-Песочная ул., д. 44, г. Казань,
420107

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА
ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
Ново-Песочная ур. 44 нчы йорт,
Казан шәһәре 420107

БОЕРЫК

28.01.2020 Казан шәһәре № 20-09

2020 елда Татарстан Республикасы
муниципаль архивларының
грант ярдәме алыр өчен бәйгесе турында

Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм башка архив документларын саклауны тәэмин итүдә, куллануда, аларны исәпкә алу, комплектлаштыру сыйфатын күтәрүдә яңа заман технологияләрен кертү, хәзерге көннең җиһазларын файдаланышка алуны оештыру; архив эше өлкәсендә ныклы югары нәтиҗәләр белән үзләрен таныткан муниципаль архивларга ярдәм итү; аларда уңайлы эш тәҗрибәсен җайга салу; җитәкчеләр һәм хезмәткәрләрнең профессиональ үсешен тәэмин итү максатында Б О Е Р А М:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы муниципаль архивларына грант ярдәме отсын өчен бәйге оештырырга һәм уздырырга (алга таба – бәйге). Сроклары – 2020 елның 27 февраленнән алып 1 апреленә кадәр.

2. 2020 елда Татарстан Республикасы муниципаль архивларына грант ярдәме отсын өчен бәйге оештырырга һәм уздырырга дигән Нигезләмәне расларга.

3. Архив эшләре һәм мәгълүмати хезмәт күрсәтү бүлегенә бәйгенең оештыру-методик ягын тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Комитетының «2019 елда Татарстан Республикасы муниципаль архивларына грант ярдәме отсын өчен бәйге оештырырга һәм уздырырга» дигән һәм 02.04.2019 датасы, 85-од номеры белән расланган Боерыгын гамәлдән чыкты дип исәпләргә.

4. Әлеге Боерык рәсми бастырылган көннән гамәлгә керә.

5. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис Г.З. Габдрахманова